# КАРАР № 54

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы утырышы

29 август 2022 ел　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Түбән Бәрәскә авылы

**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 22 нче августындагы 59 нчы номерлы карары белән расланган «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2022 елның 1 нче апрелендәге 90-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Россия Федерациясе Федераль законына, «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, 2022 елның 24 июнендәге 02-08-02/Прдп204-22-20920010 номерлы Әтнә районы прокуратурасы протесты буенча фикер алышканнан соң, Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Уставына таянып, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3 пунктның г пунктчасында «оешмалары» сүзләреннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　А.В.Фатыхова